КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** **БОЕРЫК**

2025 ел, 3 сентябрь г.Казань № б-1982

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы территориясендә җир кишәрлекләрен резервлау турында» 2004 елның 22 гыйнварындагы ПУ-26 номерлы Указы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Җир кишәрлекләрен Татарстан Республикасы дәүләт җир резервларына кертү һәм алардан алга таба файдалану мәсьәләләре буенча дәүләт хакимияте башкарма органнары, Татарстан Республикасы муниципаль районнарының һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнары, шулай ук Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Дәүләт җир резервлары фонды һәм Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Дәүләт торак фонды арасында үзара хезмәттәшлек итү тәртибен раслау турында» 2005 ел, 21 гыйнвар, 15 нче карары, Казан шәһәре муниципаль берәмлеге башкарма комитетының «Җир кишәрлекләрен Татарстан Республикасы җирләренең дәүләт резервына бирү турында» 2012 елның 11 декабрендәге 9125 номерлы карары нигезендә:

1. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының, Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Җирләрнең дәүләт резерв фондының дәүләт ихтыяҗлары өчен торак төзү максаты белән Казан шәһәренең Киров районындагы Больничная урамында урнашкан «күпфатирлы торак йортлар салу (биек йортлар салу)» рөхсәт ителгән файдалану төрендәге 0,8751 гектар гомуми мәйданлы, 16:50:280844:51 кадастр номерлы җир кишәрлеген кушымта нигезендә өч ел срок белән Татарстан Республикасы җирләренең дәүләт резервына кертү турындагы тәкъдимен кабул итәргә.

2. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына әлеге боерыкның 1 нче пункты нигезендә Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрына тиешле үзгәрешләр кертү өчен документларны Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә билгеләнгән тәртиптә кертергә.

3. Бу боерыкның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына йөкләргә.

4. Бу боерык резервлана торган җир кишәрлеге урнашу урыны буенча рәсми массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарылырга тиеш һәм басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2025 ел, 3 сентябрь, б-1982 нче
боерыгына кушымта

Территория чикләренең характерлы нокталары координатлары исемлеге
(16:50:280844:51 кадастр номерлы җир кишәрлеге)

| Җир кишәрлеге чигенең характерлы нокталары турында белешмәләр | | | | |
|---|---|---|---|---|
| Координаторлар системасы: Халыкара координатлар системасы-16 | | | | |
| Нокта но-меры | Координатлар, м | | Җирлектә беркетү тасвирламасы | Җир кишәрлеге чикләренең характерлы нокталарын билгеләүнең уртача квадрат төгәлсезлеге, м |
| | X | Y | | |
| 1 | 479110.21 | 1291156.24 | - | 0.1 |
| 2 | 479118.92 | 1291204.7 | - | 0.1 |
| 3 | 479089.44 | 1291210.93 | - | 0.1 |
| 4 | 479083.38 | 1291211.97 | - | 0.1 |
| 5 | 479094.85 | 1291282.56 | - | 0.1 |
| 6 | 479078.57 | 1291281.73 | - | 0.1 |
| 7 | 479077.64 | 1291272.98 | - | 0.1 |
| 8 | 479066.19 | 1291274.2 | - | 0.1 |
| 9 | 479066.94 | 1291281.12 | - | 0.1 |
| 10 | 479024.75 | 1291278.93 | - | 0.1 |
| 11 | 479023.63 | 1291169.23 | - | 0.1 |
| 1 | 479110.21 | 1291156.24 | - | 0.1 |